| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ЗАРЕЧЕНСК<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Зареченск авылы

29.05.2023 нче ел №5

Баулы муниципаль районы
Яңа Зареченск авыл җирлеге
территориясендә хайваннарны
хуҗасыз кайтару тыела торган урыннар
исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Яңа Зареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Башкарма комитет Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге

Карар итә:

1. Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Яңа Зареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгын хайваннарның элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз хайваннарны кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм сайтта бастырып чыгарырга

(http://www.pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Яңа Зареченск авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Р. Зәбирова